Акыллыга сүз әйттем...:
Табышмаклар
УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
М96
*Китап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комитеты ярдәмендә нәшер ителде.*
Редакторы НУРЗИДӘ НОТФУЛЛИНА
Сериянең рәссамы ЛИЛИЯ ЗОЛОНДИНОВА
Рәссамы АЛЛА АЙСЕНА
**Мөҗәһит**
Акыллыга сүз әйттем...: Табышмаклар.— Казан: Мәгариф, 2003.— 47 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1303-2
ISBN 5-7761-1303-2
© «Мәгариф» нәшрияты, 2003

Кояшлы ил, нурлы ил —
Охшаган чаптар атка.
Тырыш халкының даны
Яңгырый бар тарафка.
Нинди ил ул? Ул илдә
Сөйлиләр кайсы телдә?
*(Татарстан. Татар, рус*
*һәм башка телләрдә)*
Әткәң-әнкәңдәй газиз,
Кадерле һәм якын ул.
Боздай каты, салкын ул,
Күп вакытта ялкын ул.
*(Туган тел)*
Йөзәм, ләкин суда түгел,
Йөзәм сезнең өстә мин.
Шат чагында ап-ак булам,
Кайчак кара төстә мин.
*(Болыт)*
Тотам дисәң тоттырмый,
Ялык-йолык итә ул.
Болыт белән килә дә
Болыт белән китә ул.
(Яшен)
*Ярты икмәк, туп, урак,*
*Торган җире бик ерак.*
*(Ай)*
Чулпан да ул, Зөһрә дә,
Венера да кайчакта.
Шундый матур балкып тора
Кояш уянган чакта.
*(Йолдыз)*
Колач җәеп каршы ала,

Сулышларны киңәйтә.
Кайчак ул караңгы, шомлы...
Исемен аның кем әйтә?
*(Урман)*
Мине алып йөрсәгез,
Карурманга керсәгез,
Диңгезләрдә йөзсәгез,
Онытмагыз сез шуны —
Белмәссез адашуны.
*(Компас)*
Сайрар кошлар патшасы ул,
Җырчылар көнләшерлек.
Дөньяда бер кош та юктыр
Шул кошка тиңләшерлек.
*(Сандугач)*
Ап-ак күлмәген кигән дә
Яшел шәлен ябынган.
Башкалардан өстен тора
Зифалыгы ягыннан.
*(Каен)*
Күп чәчәкләр белән бергә
Бер үк җирдә үсәләр.
Шифасы күп булган өчен,
Чәен ясап эчәләр.
*(Мәтрүшкә)*
Баш очымда эленеп тора,
Ә моңнары түгелеп тора.
Иртәгә көн нинди булыр —
Җырларыннан беленеп тора.
*(Тургай)*
Бодайда да, арышта да,
Арпада да булам мин.
Җәйләр матур килә икән,
Бөртек белән тулам мин.
*(Башак)*
Җылы яктан кайтуына
Өйләр ясап куябыз.
Хәтта кереп тә карамый,
Ошамаса оябыз.
*(Сыерчык)*
Өе биектә булса да,
Үзе бер генә катлы.
Тәрәзәсе юк, аяклы,
Хуҗалары — канатлы.
*(Сыерчык оясы)*
Кар да түгел, ә ява:
Ап-ак булды бар һава.
Кыш та түгел югыйсә,
Җәйге җылы җил исә.

*(Тупыл мамыгы яву)*
Кап-кара түбәтәй кигән,
Ап-актыр яңаклары.
Яшькелт-сары түшкәйләре,
Карасу канатлары.
*(Песнәк)*
Тук та тук дип утыра ул,
Тук түгелдер, ачтыр ул.
Агачлардагы кортларны
Чүпләргә бик мачтыр ул.
*(Тукран)*
Төп шөгыле — караклык,
Төсе — аклы-каралы.
Ә койрыгы — сиртмәле,
Күрсәң, исең китмәле.
*(Саескан)*
Кайрым яшел, яфракларым
Сөйләшәләр җилсез дә.
Йорт салырга теләсәгез,
Бүрәнә булам сезгә.
*(Усак)*
Туганда ук эшләпәсен
Киеп туа.
Тик шулай да күләгәдә
Гомере уза.
*(Гөмбә)*
«Тырыш»ның соңгы хәрефен
Алыштырып куйсагыз,
Миңа китереп салырсыз,
Гөмбә, җиләк җыйсагыз.
*(Тырыс)*
Сөттәй ап-ак тамчылар
Яшел болыт астында.
Хуш исләрен таратып
Җемелдиләр каршымда.
*(Энҗе чәчәк)*
Сайрамый да, җырламый да,
Тик кычкырып моңлана.
Ул кычкыргач, су керергә
Вакыт җитә, соңлама.
*(Күке)*
Йә су белән юына,
Йә тузанда коена.
Үзе безгә сыена.
Гомер буе безнең белән
Яшәргә дип җыена.
*(Чыпчык)*
Җепшек бураны да бар,
Тәмле боткасы да бар.

Аның карасы да бар,
Хәтта аласы да бар.
*(Карга)*
Җәй дә гөр-гөр,
Кыш та гөр-гөр
Гөрли дә гөрли генә.
Түбә астында яши ул
Михнәтләр күрми генә.
*(Күгәрчен)*
Бәбкә-фәлән күрмәмме дип
Әйләнә баш очымда.
Күзен дә йоммый ата каз
Менә шуның өчен дә.
*(Тилгән)*
Ялгыш кына тисәгез дә,
Елатабыз, чагабыз.
Безгә үпкәли күрмәгез,
Шул саклану чарабыз.
*(Кычыткан)*
Ул борыны, ул канаты!..
Ә күзләре ут кебек.
Хәтта куян мескеннәргә
Очып төшә ук кебек.
*(Бөркет)*
Аяклары озын булгач,
Йөриләр биеп кенә.
«Туган җирләрдә күбрәк
Тор-рыйк без», — диеп кенә.
*(Торна)*
Тәне тулы тәңкәсе,
Елга — аның әнкәсе.
*(Балык)*
Зәңгәр дулкыннар өстендә
Йөзәләр дә очалар...
Әллә шуны да белмисең?
Балык тота ич алар.
*(Акчарлак)*
Балык кебек йөзә ул,
Океаннар гизә ул.
Баласына, кадерләп,
Тәмле сөт имезә ул.
*(Кит)*
Балык дисәң дә балык!..
Тора халык таң калып.
Тәмле прәннек, кәнфитне
Ашый кулыңнан алып.
*(Дельфин)*
Түп-түгәрәк кара күз,
Сап-сары керфекләре.

Ул ярата кояшны,
Без — аның бөртекләрен.
*(Көнбагыш)*
Төркем-төркем тезелешеп,
Туган якка кайталар.
Өйдәгеләр кызыгып кала:
«Менә бәхетле алар...»
*(Казлар)*
Өйдәгеләр: «Бак-бак»,— ди.
Кырдагылар: «Сак-сак,— ди.—
Аучылар күреп алыр,
Без тавыш чыгарсак»,— ди.
*(Үрдәк)*
Куркыныч хәл була калса,
Көрткә генә чума ул.
Бераз гына тын тора да
Тагын килеп чыга ул.
*(Көртлек)*
Кош булса да оча алмый,
Кызыл күрсә — кабара.
Ни икәнен беләсеңме?
Йә әле әйтеп кара?
*(Күркә)*
Төсем наратныкы кебек,
Тик кыска шул энәләр.
Яңа елны каршыларга
Мине сорап киләләр.
*(Чыршы)*
Күзләре — мәченекеләр,
Колаклары — локатор.
Бик тә күрергә теләсәң,
Йокламыйча саклап тор.
*(Мәче башлы ябалак)*
Кешеләргә бик файдалы
Кош-корт булып саналам.
Тырышмыйча да елына
Йөзләп йомырка салам.
*(Тавык)*
Кечкенә көнбагыш кебек
Чәчәк булам мин үзем.
Таҗларымны санап кара,
Әгәр булсаң бик түзем.
*(Ромашка)*
Безли-безли
Нидер эзли.
Тешләмичә
Тәки түзми.
*(Черки)*
Оча-оча арыйлар да

Бер ботакка сарыйлар.
Аннан ары хуш исле бал
Җыю ягын карыйлар.
*(Бал кортлары)*
Минсез мунчала да булмый,
Минем бал — иң тәмлесе.
Башкаларга караганда
Мин — иң йомшак тәнлесе.
*(Юкә)*
Аллы-гөлле чәчәкләрне
Кетер-кетер ашый ул.
Шуннан ап-ак сөтләр ясап,
Көн дә безгә ташый ул.
*(Сыер)*
Ярты икмәк, туп, урак,
Торган җире бик ерак.
*(Ай)*
Чулпан да ул, Зөһрә дә,
Венера да кайчакта.
Шундый матур балкып тора
Кояш уянган чакта.
*(Йолдыз)*
Колач җәеп каршы ала,
Сулышларны киңәйтә.
Кайчак ул караңгы, шомлы...
Исемен аның кем әйтә?
*(Урман)*
Мине алып йөрсәгез,
Карурманга керсәгез,
Диңгезләрдә йөзсәгез,
Онытмагыз сез шуны —
Белмәссез адашуны.
*(Компас)*
Сайрар кошлар патшасы ул,
Җырчылар көнләшерлек.
Дөньяда бер кош та юктыр
Шул кошка тиңләшерлек.
*(Сандугач)*
Ап-ак күлмәген кигән дә
Яшел шәлен ябынган.
Башкалардан өстен тора
Зифалыгы ягыннан.
*(Каен)*
Күп чәчәкләр белән бергә
Бер үк җирдә үсәләр.
Шифасы күп булган өчен,
Чәен ясап эчәләр.
*(Мәтрүшкә)*
Баш очымда эленеп тора,

Ә моңнары түгелеп тора.
Иртәгә көн нинди булыр —
Җырларыннан беленеп тора.
*(Тургай)*
Бодайда да, арышта да,
Арпада да булам мин.
Җәйләр матур килә икән,
Бөртек белән тулам мин.
*(Башак)*
Җылы яктан кайтуына
Өйләр ясап куябыз.
Хәтта кереп тә карамый,
Ошамаса оябыз.
*(Сыерчык)*
Өе биектә булса да,
Үзе бер генә катлы.
Тәрәзәсе юк, аяклы,
Хуҗалары — канатлы.
*(Сыерчык оясы)*
Кар да түгел, ә ява:
Ап-ак булды бар һава.
Кыш та түгел югыйсә,
Җәйге җылы җил исә.
*(Тупыл мамыгы яву)*
Кап-кара түбәтәй кигән,
Ап-актыр яңаклары.
Яшькелт-сары түшкәйләре,
Карасу канатлары.
*(Песнәк)*
Тук та тук дип утыра ул,
Тук түгелдер, ачтыр ул.
Агачлардагы кортларны
Чүпләргә бик мачтыр ул.
*(Тукран)*
Төп шөгыле — караклык,
Төсе — аклы-каралы.
Ә койрыгы — сиртмәле,
Күрсәң, исең китмәле.
*(Саескан)*
Кайрым яшел, яфракларым
Сөйләшәләр җилсез дә.
Йорт салырга теләсәгез,
Бүрәнә булам сезгә.
*(Усак)*
Туганда ук эшләпәсен
Киеп туа.
Тик шулай да күләгәдә
Гомере уза.
*(Гөмбә)*

«Тырыш»ның соңгы хәрефен
Алыштырып куйсагыз,
Миңа китереп салырсыз,
Гөмбә, җиләк җыйсагыз.
*(Тырыс)*
Сөттәй ап-ак тамчылар
Яшел болыт астында.
Хуш исләрен таратып
Җемелдиләр каршымда.
*(Энҗе чәчәк)*
Сайрамый да, җырламый да,
Тик кычкырып моңлана.
Ул кычкыргач, су керергә
Вакыт җитә, соңлама.
*(Күке)*
Йә су белән юына,
Йә тузанда коена.
Үзе безгә сыена.
Гомер буе безнең белән
Яшәргә дип җыена.
*(Чыпчык)*
Җепшек бураны да бар,
Тәмле боткасы да бар.
Аның карасы да бар,
Хәтта аласы да бар.
*(Карга)*
Җәй дә гөр-гөр,
Кыш та гөр-гөр
Гөрли дә гөрли генә.
Түбә астында яши ул
Михнәтләр күрми генә.
*(Күгәрчен)*
Бәбкә-фәлән күрмәмме дип
Әйләнә баш очымда.
Күзен дә йоммый ата каз
Менә шуның өчен дә.
*(Тилгән)*
Ялгыш кына тисәгез дә,
Елатабыз, чагабыз.
Безгә үпкәли күрмәгез,
Шул саклану чарабыз.
*(Кычыткан)*
Ул борыны, ул канаты!..
Ә күзләре ут кебек.
Хәтта куян мескеннәргә
Очып төшә ук кебек.
*(Бөркет)*
Аяклары озын булгач,
Йөриләр биеп кенә.

«Туган җирләрдә күбрәк
Тор-рыйк без», — диеп кенә.
*(Торна)*
Тәне тулы тәңкәсе,
Елга — аның әнкәсе.
*(Балык)*
Зәңгәр дулкыннар өстендә
Йөзәләр дә очалар...
Әллә шуны да белмисең?
Балык тота ич алар.
*(Акчарлак)*
Балык кебек йөзә ул,
Океаннар гизә ул.
Баласына, кадерләп,
Тәмле сөт имезә ул.
*(Кит)*
Балык дисәң дә балык!..
Тора халык таң калып.
Тәмле прәннек, кәнфитне
Ашый кулыңнан алып.
*(Дельфин)*
Түп-түгәрәк кара күз,
Сап-сары керфекләре.
Ул ярата кояшны,
Без — аның бөртекләрен.
*(Көнбагыш)*
Төркем-төркем тезелешеп,
Туган якка кайталар.
Өйдәгеләр кызыгып кала:
«Менә бәхетле алар...»
*(Казлар)*
Өйдәгеләр: «Бак-бак»,— ди.
Кырдагылар: «Сак-сак,— ди.—
Аучылар күреп алыр,
Без тавыш чыгарсак»,— ди.
*(Үрдәк)*
Куркыныч хәл була калса,
Көрткә генә чума ул.
Бераз гына тын тора да
Тагын килеп чыга ул.
*(Көртлек)*
Кош булса да оча алмый,
Кызыл күрсә — кабара.
Ни икәнен беләсеңме?
Йә әле әйтеп кара?
*(Күркә)*
Төсем наратныкы кебек,
Тик кыска шул энәләр.
Яңа елны каршыларга

Мине сорап киләләр.
*(Чыршы)*
Күзләре — мәченекеләр,
Колаклары — локатор.
Бик тә күрергә теләсәң,
Йокламыйча саклап тор.
*(Мәче башлы ябалак)*
Кешеләргә бик файдалы
Кош-корт булып саналам.
Тырышмыйча да елына
Йөзләп йомырка салам.
*(Тавык)*
Кечкенә көнбагыш кебек
Чәчәк булам мин үзем.
Таҗларымны санап кара,
Әгәр булсаң бик түзем.
*(Ромашка)*
Безли-безли
Нидер эзли.
Тешләмичә
Тәки түзми.
*(Черки)*
Оча-оча арыйлар да
Бер ботакка сарыйлар.
Аннан ары хуш исле бал
Җыю ягын карыйлар.
*(Бал кортлары)*
Минсез мунчала да булмый,
Минем бал — иң тәмлесе.
Башкаларга караганда
Мин — иң йомшак тәнлесе.
*(Юкә)*
Аллы-гөлле чәчәкләрне
Кетер-кетер ашый ул.
Шуннан ап-ак сөтләр ясап,
Көн дә безгә ташый ул.
*(Сыер)*
Канатлары кашың кебек,
Оялары — балчыктан.
Чебен-черки тотып кайта:
Балалары ачыккан.
(Карлыгач)
*Әллә мөгезе борынга,*
*Әллә борын мөгезгә*
*Охшаганга, исемне дә*
*Кушканнардыр үзенә.*
(Мөгезборын)
*Пычкы, балта тотмый гына,*
*Ялгызы агач кисә.*

*Шундук суга чума үзе,*
*Куркыныч булды исә.*
*(Кондыз)*

Дус булса да сөйләшми,
Күп ишетә, күп күрә.
Үзенә йорт төзедек,
Хезмәт иткәнгә күрә.
*(Эт)*
Гомер буе үргән ул,
Җепләр сузып йөргән ул.
Тозагында азык көтеп,
Шулай көнен күргән ул.
*(Үрмәкүч)*
Үзеннән зур йөк күтәреп
Чаба да чаба гына.
Ә өен күзәтә, менеп,
Үләннәр сабагына.
*(Кырмыска)*
Өрә белсә, кеше белән
Дус булырга уйлый ул.
Әкиятләр искә төшсә,
Елый-елый улый ул.
*(Бүре)*
Агачлардан агачларга
Мин бик оста сикерәм.
Чикләвек, нарат күркәсе
Ашап кына көн күрәм.
*(Тиен)*
Гомерем озын, үзем — нык,
Ябалдашларым да киң.
Чикләвекләрем бар хәтта,
Йә, кайсыгыз миңа тиң?!
*(Имән)*
Хәйләкәр дип тә йөртәләр,
Ялагай дип атыйлар.
Туны белән койрыгын
Бөтен җирдә мактыйлар.
*(Төлке)*
Кышлар буе өендә
Йоклый көнен-төнен дә.
Бик яратканга күрә,
Төшенә дә бал керә.
*(Аю)*
Кабан күлендә яшәми,
Урманнарда көн күрә.
Балаларын ияртә дә
Чирәм җирләрне сөрә.
*(Кабан дуңгызы)*

Гел сыер инде үзе,
Тик тармаклы — мөгезе.
*(Поши)*
Үзем куркак булсам да,
Балалар бик ярата.
Хәтта шигырь сөйлиләр
Мин наянга карата.
*(Куян)*
Камчы кебек шуышам,
Күренмәскә тырышам.
Мине борчып йөрмәгез,
Ялгыш баса күрмәгез.
*(Елан)*
Тауларда кеше сыярлык
Тишекләр ясый ала.
Җәен азык туплый, кышка
Тирән йокыга тала.
*(Бурсык)*
Бодайларны, арышларны
Җыеп куя өненә.
Шулай әзерлек чарасын
Күрә ул кыш көненә.

Арт аякларына басып
Сызгыра бар көченә.
Күз ачканчы кереп чума
Оясының эченә.
*(Йомран)*
Су буенда туебыз,
Чебен-черки — сыебыз.
*(Бака)*
Никтер миңа бирәр матур
Исем дә тапмаганнар.
Җир астыннан йөргәнгәме,
Сукыр дип атаганнар...
*(Сукыр тычкан)*
Мин үзем усал да түгел,
Тик тоталар читлектә.
Сезнең кебек сөйләшергә
Өйрәнермен ничек тә.
*(Тутый кош)*
Киемнәре: ыңгырчак һәм
Камыт, дуга, дилбегә.
Инде ничә гасыр буе
Кешеләргә бил бөгә.
*(Ат)*
Әрекмәндәй зур колак,
Аяклары — бер колач.
Борыны җиргә тигән,

Килгән ул ерак илдән.
*(Фил)*
Муен булса, шундый булсын:
Башым һәрчак югары.
Миннән биек җәнлекләрне
Күргәнегез юк әле.
*(Жираф)*
Безнең сурәт мөһерләргә,
Диварларга уелган.
Саныбыз кимеп барганга,
Безне аулау тыелган.
*(Барс)*
Киекләрнең патшасы мин,
Курыкмагыз мин барда.
Рөхсәт бирдем кешеләргә
Исемемне кушарга.
*(Арыслан)*
Гайрәт, җитезлек ягыннан
Арысланга бирешмим.
Буйлы киемемне салмыйм,
Яшим шушы килеш мин.
*(Юлбарыс)*
Дөньяда мин иң еракка,
Биеккә сикерүче.
Баламны сумкамда гына
Үстереп җиткерүче.
*(Көнгерә)*
Ерткычның да ерткычы ул,
Күлләрдә качып ята.
Кошлар тешне чистартсын дип,
Авызын ачып ята.
*(Крокодил)*
Башта күктә очып йөри,
Аннан җиргә елыша.
Тизрәк тотып калабыз, дип,
Балалар җыелыша.
*(Кар)*
Кешеләр дә, безгә охшап,
Салкында су керәләр.
Яланаяк карда йөреп,
Бәкегә сикерәләр.
*(Морж)*
Кешеләрнең дуслары без,
Салкыннарга түзәбез.
Канатларны ишкәк итеп,
Чумабыз да йөзәбез.
*(Пингвин)*
Бакчабызны тычканнардан,
Корткычлардан саклый ул.

Энәләре күп булса да,
Беркемгә дә сатмый ул.

*(Керпе)*

Бер карасаң, тышта йөри,
Бер карасаң — йортта ул.
Йортым ерак калмасын, дип,
Аркасында йөртә ул.

*(Ташбака)*

Йөген төяп челләдә,
Армый йөри чүлләрдә.

*(Дөя)*

Типсә тимер өзәр ул,
Чапса җилне узар ул.

*(Тәвә кошы)*

Кош-корт, җәнлек, үсемлекләр,
Бетәбез дип торганда,
Бирешмәскә булганнар:
Саклар диеп, яклар диеп,
Аңа кереп тулганнар.
*(«Кызыл китап»)*

ЛИТЕРАТУРНО-ХУДОЖЕСТВЕННОЕ ИЗДАНИЕ
Для детей и юношества
**Музагит**
**(**Ахметзянов Музагит Загитович)
**УМНЫЙ РАССУДИТ...**
Загадки
*(на татарском языке)*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Л. И. Матвеева*
Компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*
Корректоры *Р. Ә. Фәйзуллина*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүче *Л. Р. Вафина*
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 09.06.2003. Форматы 84ә100$^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 4,68 + форз. 0,39. Нәшер-хисап табагы 3,26 + форз. 0,7.
Тиражы 8000 д. Заказ Я-242.
«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.